**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИВАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.1а, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Үзек урамы, 1а йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

**17 ноябрь 2022 ел** **№ 11**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«Биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында»**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы Указының 4 пункты, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 декабрендәге 98 номерлы «Ивашкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Ивашкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәне раслау турында» карары нигезендә (һәм Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының 2022 елның 19 маендагы 67 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) **КАРАР БИРӘМ:**

1. Биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ивашкино авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе С.В. Иванова

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 17 ноябрендәге
11 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:
   - Башкарма комитет җитәкчесе;
   - Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары;